# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«16» сентябрь, 2019 ел Яр Чаллы № 3860

2014 елның 26 декабрендәге «2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын раслау турында» 7132 санлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының «2018-2020 елларга коррупциягә каршы тору милли планы турында» 2018 елның 29 июнендәге 378 номерлы указын, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» турында 512 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 10 сентябрендәге «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» турында 763 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 сентябрендәге 495 номерлы карарын үтәү йөзеннән

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 декабрендәге «2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын раслау турында» 7132 санлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемендә, 1 пунктта «2015-2021» саннарын «2015-2022» саннарына алыштырырга;

программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2015 – 2022» саннарын «2015 – 2022» саннарына алыштырырга;

«Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2015-2021» саннарын «2015-2022» саннарына алыштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме | Программаны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты средстволары хисабына финанслауның гомуми күләме 180000 су тәшкил итә | |
| | 2015 | 20000 |
| | 2016 | 20000 |
| | 2017 | 20000 |
| | 2018 | 20000 |
| | 2019 | 20000 |
| | 2020 | 20000 |
| | 2021 | 20000 |
| | 2022 | 40000 |
| | Искәрмә: финанслау күләме фараз характерында һәм аңа, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; | |

«Программаның максат һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында беренче абзацта «2021 ел азагына» сүзләрен «2022 ел азагына» сүзләренә алыштырырга;

программаның II бүлегендә:

унберенче абзацта «2015-2021» саннарын «2015-2022» саннарына алыштырырга;

программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2015-2022 елларга программаны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты средстволары хисабына финанслауның гомуми күләме 180000 сум тәшкил итә, шул исәптән:

| Ел | Татарстан Республикасы бюджет средстволары күләме |
|---|---|
| 2015 | 20000 |
| 2016 | 20000 |
| 2017 | 20000 |
| 2018 | 20000 |
| 2019 | 20000 |
| 2020 | 20000 |
| 2021 | 20000 |
| 2022 | 40000 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм аңа, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, программа чараларын тормышка ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаларны файдалану күздә тотыла»;

программаның V бүлеге бишенче абзацында «2021 елга» сүзләрен «2022 елга» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацта «2015-2021» саннарын «2015-2022» саннарына алыштырырга»;

программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов